ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 411 от «27» 10 2025 г.

2026 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза уздыру планын раслау турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 июнендәге158 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза уздыру планын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының (http://www.pravo.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://www.mamadysh.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.В.Потреяхинага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.М.Никифоров

0000012975

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
27 10 2025 ел,
№ 411 санлы карарына
кушымта

2026 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза уздыру
ПЛАНЫ

| № т/б | Норматив хокукый акт исемнәре һәм реквизитлары (НХА) | НХА эшләүне гамәлгә ашыручы җайга салучы орган, бүлекчә исеме | НХАга карата экспертиза турында бәяләмә бирү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2025 елның 25 мартындагы «2025-2026 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» максатчан программасы турында» 118 нче карары | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге | Июль 2026 ел |
| 2. | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 22 декабрендәге «Кулланучылар кооперациясе тарафыннан Мамадыш шәһәреннән 11 км дан артык ераклыкта урнашкан аз халыклы торак пунктларга көнкүреш кирәк- яраклары китерү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Мамадыш муниципаль район бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 1593 нче карары | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | Сентябрь 2026 ел |